*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен олимпиада биремнәре**

***2017/2018 нче уку елы*** **IX сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут** **Максималь балл -60**

**I. Кайсы рәттәге сүзтезмәләрдә хаталар бар? Сәбәбен аңлатыгыз. Дөрес вариантларны языгыз.**

а) 125 укучыга, 343 кешенең, 62 китаптан, 23 дәфтәрдә

ә) 14 агачларны, 7 чыршыларга, 9 каеннарда, 17 кызлардан

**II. Билгеләнгән кушымчаларны чагыштырыгыз. Кайсы рәттәге сүзләрдә генә ясагыч кушымчалар бирелгән?**

а) җыр**лаш**, уй**лаш**, эш**ләш**;

ә) сер**ләш**, киңәш**ләш, дуслаш**;

б) сак**лаш**, якын**лаш**, ерак**лаш.**

**III. Сүзләрдәге билгеләнгән авазарның әйтелешендәге аерманы күрсәт.**

а) [а]ваз, т[о]рна, т[ы]рыш, [э]шләр;

ә) ст[а]рт, лим[о]н, в[ы]шка, [э]лектр.

**IV. Мәкальне укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**

*Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы.*

а) сузык авазлары белән аерылып торган сүзне аңлатып языгыз;

ә) тартык авазлары белән аерылып торган сүзне аңлатып языгыз;

б) әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне аңлатып языгыз;

в) исемләшкән сүз төркемнәрен аңлатып языгыз;

г) җөмлә кисәкләрен билгеләгез;

д) җөмләгә характеристика бирегез;

е) сүз турында өч мәкаль өстәп языгыз.

**V. Иҗади бирем.**

**“Энем (сеңлем) 1 нче сыйныфка барырга әзерләнә” дигән темага 9 җөмләдән торган хикәя төзеп языгыз.**